РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 17 марты 129№

2020 елга гражданнар керменең һәм салым
салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик
күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Республикасы Законы нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен расларга. (1 нче кушымта).

2. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 12 августындагы 283 номерлы «2019 елга гражданнар керменең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының авыл җирендә яшь гаиләләр һәм яшь белгечләр өчен торак төзелешен субсидияләү программасын үтәү бүлегенә әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда кулланырга.

5. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының яшь гаиләләр һәм яшь белгечләр өчен торак төзелешен субсидияләү программасын үтәү бүлеге башлыгына йөкләнә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Башкарма комитетының
2020 елның 17 мартындагы 129 номерлы Карарына
1 нче кушымта

2020 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган мөлкәт хакының иң чик күләмнәре

| Гаилә әгъзалары саны | Гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган мөлкәт хакының иң чик күләме (сум) | Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме (сум) |
|---|---|---|
| 1 | 1551792 | 31035,84 |
| 2 | 1975008 | 19750,08 |
| 3 | 2539296 | 17013,28 |
| 4 | 3385728 | 17013,28 |
| 5 | 4232160 | 17013,28 |
| 6 | 5078592 | 17013,28 |
| 7 | 5925024 | 17013,28 |